РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» июля 2022 ел г. Альметьевск № 1498

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясындагы 3 пункты, 2021 елның 31 маенда Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан теркәлгән Россия Финанс министрлыгының 2020елның 30 декабрендәге 340н номерлы «Эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан рәсмиләштерелә торган документларның формаларын раслау турында» боерыгы нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2014 елның 30 декабрендәге 3806 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2014 елның 30 декабрендәге 3806 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 25 маендагы 720 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольдә тоту вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 02 июлендәге 921 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контрольдә тоту вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 02 июлендәге 921 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 23 декабрендәге 1897 номерлы карары;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Зак. № 305-2000